Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кычытканлы авыл җирлеге Кычытканлы авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

«13» ноябрь 2020 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2020 елның 13 ноябрендә узган: «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Кычытканлы авыл җирлегенең Кычытканлы авылы территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм аларның тол калган хатыннарыннан тыш, 2021 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Кычытканлы авыл җирлеге торак пункты чикләрендә юлларны ремонтлау һәм карап тоту, шул исәптән сезонлы карап тоту (Кычытканлы авылы юлларын кардан чистарту өчен махсус техника яллау)» мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 349 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 216 кеше катнашты.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 177 кеше тавыш бирде;
«ЮК» позициясе өчен җыенның 39 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:
1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кычытканлы авыл җирлеге Кычытканлы авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Кычытканлы авыл җирлегенең Кычытканлы авылы территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм аларның тол калган хатыннарыннан тыш, 2021 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Кычытканлы авыл җирлеге торак пункты чикләрендә юлларны ремонтлау һәм карап тоту, шул исәптән сезонлы карап тоту (Кычытканлы авылы юлларын кардан чистарту өчен махсус техника яллау)» мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Кычытканлы авылы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кычытканлы авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче Ф.Р. Сабиров

Кычытканлы авыл җирлеге башлыгы Ф.Р. Сабиров